**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Беловка авыл җирлеге башкарма комитеты**

**КАРАР**

**№ 3** **20.04.2018 ел**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында**

« Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль Законына, «янгын куркынычсызлыгы турында» 21.12.1994 №69-ФЗ Федераль Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 20.09.2016 №947 карары нигезендә, «Беловское авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә янгынга каршы тотрыклылыкны арттыру максатларында Беловка авыл җирлеге территориясендәге торак пунктларны:

1. Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге торак пунктларының гомуми файдаланудагы җирләрендә учаклар ягу, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру тыела, тик иң якын төзелешләргә кадәр ара 50 метрдан да ким булмаган урыннарда җилсез һава торышында һәм чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны яндыруны даими контрольдә тоту шартларында гына.
2. Әлеге карар торак пункт территориясендә махсус янгынга каршы режим кертелгән чорда үз көчен җәелдерми.
3.Карар имзаланган көннән үз көченә керә.
4.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru)
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Беловка авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе И. Р. Мәхмүтов